ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 июля 2022 ел № 3306

Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 24 декабрендәге 7379 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 9 декабрендәге 6589 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 3530 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 5760 номерлы, 2020 елның 17 августындагы 3995 номерлы, 2021 елның 15 июнендәге 4013 номерлы, 2021 елның 1 сентябрендәге 5766 номерлы, 2021 елның 1 октябрендге 6434 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү һәм саклау тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 11.1 пункт өстәргә:

«11.1. Капиталь төзелеш объекты булмаган законсыз урнаштырылган объектларны ачыклау, демонтажлау, күчерү эшләрен оештыруны, «Персональ мәгълүматлар турында» Федераль закон таләпләрен үтәп, район хакимиятенең вазыйфаи затлары гамәлгә ашыралар;

2) 33-36 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«33. Район хакимиятенең вазыйфаи затлары тарафыннан, Башкарма комитет карары таләпләрен бозып күчмә корылма (алга таба – күчмә сәүдә

объекты) урнаштыру факты ачыкланганда, район хакимиятенең вазыйфаи затлары әлеге нигезләмәгә 10 нчы кушымтада каралган форма буенча акт төзиләр.

34. Объект ачыкланганда күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) билгеләнгән очракта, район хакимиятенең вазыйфаи заты күчмә сәүдә объекты милекчесенә (хуҗасына) карата ТР КОАП 2.6 статьясы буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзи, шулай ук, әлеге нигезләмәгә 7 нче кушымтада каралган форма буенча күрсәтмә тапшырылган вакыттан башлап бер сәгать эчендә, имза куйдырып, милекчегә (хуҗага) күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урынны ирекле рәвештә бушату турында күрсәтмә тапшыра.

Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы), аңа күрсәтмә бирелгәннән соң бер сәгать эчендә Башкарма комитет карары таләпләрен бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урынны бушатмаса, район хакимиятенең вазыйфаи заты 11 нче кушымтада каралган форма буенча таләпләрне бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объектын күчерү турында акт төзи һәм Башкарма комитет карары таләпләрен бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объектын саклау мәйданчыгына күчерү буенча кичектергесез эшләрне гамәлгә ашыра.

35. Күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урында күчмә сәүдә объекты милекчесен (хуҗасын) билгеләү мөмкинлеге булмаганда, район хакимиятенең вазыйфаи заты бер сәгать эчендә, күрсәтмә тапшыру өчен күчмә сәүдә объекты милекчесен (хуҗасын) билгеләү һәм аңа хәбәр итү буенча эшләрне гамәлгә ашыра, 11 нче кушымтада каралган форма буенча күчмә сәүдә объектын күчерү турында акт төзи һәм ачыклау турында акт төзелгән вакыттан башлап бер сәгать эчендә милекче (хуҗа) билгеләнмәсә, Башкарма комитет карары таләпләрен бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урынны бушату һәм аны саклау мәйданчыгына күчерү буенча кичектергесез эшләрне гамәлгә ашыра.

36. Башкарма комитет карары таләпләрен бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объектлары ачыклану турында мәгълүмат районнар хакимиятләренең вазыйфаи затлары тарафыннан «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла.»;

3) 37-38 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

4) 7 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралганча бәян итәргә;

5) 10 нчы кушымтаны 2 нче кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

6) 3 нче кушымтада каралганча 11 нче кушымта өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма

комитетның Үзәк районы хакимияте башлыгы Э.Р. Фәттаховка, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 1 июлендәге
3306 номерлы карарына
1 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты
булмаган законсыз
урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау, күчерү
һәм саклау тәртибе турында
нигезләмәгә
7 нче кушымта

Билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган
күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урынны ирекле рәвештә бушату турында
күрсәтмә

N ______ "__" _________ 202__ ел вакыты _____ сәг. ________ мин.

Кемгә: ______________________________________________________________
(күчмә сәүдә объекты милекчесенең (хуҗасының) Ф.И.А.и.)

тапшырылган вакыттан башлап бер сәгать эчендә ирекле рәвештә үз көчең белән һәм үз хисабыңа ______________________________________________ адресы буенча урнаштырылган күчмә сәүдә объекты
_____________________________________________________________________
(күрсәтелә: лоткалар, автокибетләр, автофургоннар, автолавкалар, автоцистерналар, арбалар һәм башка шундый ук объектлар)
урнаштырылган урынны бушатырга кирәк,
шулай ук күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урынны _____ сәг. ______ мин. кадәр элекке хәленә китерергә.

Әлеге күрсәтмә үтәлмәгән очракта, күчмә сәүдә объекты мәҗбүри рәвештә саклау урынына күчереләчәк.

Күрсәтмә белән танышты
_______________________________________________ районы хакимияте вәкиле
(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)
Милекчесе (хуҗа)
(Ф.И.А.и., күчмә сәүдә объекты ___________________________________
(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)
Шаһит 1: ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Шаһит 2: ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) күрсәтмәне алудан баш тартты
_______________________________________________ районы хакимияте вәкиле
(вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)
Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) _____________________________
(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)
Шаһит 1: ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Шаһит 2: ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Кушымта: күчмә сәүдә объектын урнаштыру фотографиясе

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 1 июлендәге
3306 номерлы карарына
2 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты
булмаган законсыз
урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибе
турында нигезләмәгә
10 нчы кушымта

Таләпләрне бозып урнаштырылган
күчмә сәүдә объектын ачыклау турында акт

"___" ________ 20___ ел ____ сәг. ____ мин. ________________________________ адресы буенча урнаштырылган күчмә сәүдә объектын "___" ________ 20_____ елда ачыклау турында әлеге акт төзелде: (күчмә сәүдә объекты адресы һәм урнашу урыны, транспорт чарасының (күчмә сәүдә объектының) маркасы һәм номеры

Күчмә сәүдә объектының кемнеке булу турында мәгълүмат
_______________________________________________________________
(күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) мәгълүматлары, Ф.И.А.и., теркәлү адресы, ИНН)

Акт күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) катнашында (булмаганда) төзелде:

_______________________________________________ районы хакимияте вәкиле
(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)

Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) ______________________________
(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)

Шаһит 1: _______________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Шаһит 2: _______________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Кушымта: күчмә сәүдә объектын урнаштыру фотографиясе.

Күчмә сәүдә объекты милекчесен (хуҗасын) административ җаваплылыкка тарту турында беркетмә ____________________ төзелде.
Күчмә сәүдә объекты урнаштырылган урын ирекле рәвештә бушатылды
_______________________________________________ районы хакимияте вәкиле
(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)

Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) ______________________________
(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)

Шаһит 1: _______________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Шаһит 2: _______________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Күчмә сәүдә объекты ______________________________________
адресы буенча саклау стоянкасына күчерелде

______________________________________ районы хакимияте вәкиле
(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)
Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) ______________________
(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)

Шаһит 1: ______________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)
Шаһит 2: ______________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 1 июлендәге
3306 номерлы карарына
3 нче кушымта

Капиталь төзелеш объекты
булмаган законсыз
урнаштырылган объектларны
ачыклау, демонтажлау,
күчерү һәм саклау тәртибе
турында нигезләмәгә
11 нче кушымта

Таләпләрне бозып урнаштырылган
күчмә сәүдә объектын күчерү турында акт

"___" ________ 20___ ел ____ сәг. ____ мин. ____________________________________________ адресы буенча урнаштырылган күчмә сәүдә объектын (транспорт чарасын) "___" ________ 20___ ел ____ сәг. ____ мин. күчерү турында әлеге акт төзелде:

1) транспорт чарасының маркасы, төсе __________________________________________________________;

2) дәүләт теркәве билгесе (булган очракта) ______________________________________________________,
башка идентификация мәгълүматлары __________________________________________________________;

3) транспорт чарасының төгәл тасвирламасы ______________________________________________________
______________________________________________________________________________________;

4) төяү һәм күчерү ысулы, төяүне һәм күчерүне гамәлгә ашыручы оешма ______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________________;

5) таләпләрне бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объектын ачыклау актын төзү һәм күчмә сәүдә объекты милекчесенә (хуҗасына) хәбәр итү датасы, вакыты ______________________________________________________________________________________;

6) милекчегә хәбәр итү турында мәгълүмат яки транспорт чарасының хуҗасы турында мәгълүматлар булмау турындагы мәгълүмат __________________________________________________________;

7) милекче тарафыннан транспорт чарасын күчерү турында таләпләр үтәлмәү турында мәгълүмат ______________________________________________________________________________.

Кушымталар:

1) транспорт чарасының эчендә күренеп торган мөлкәт исемлеге;

2) транспорт чарасы эчендәге мөлкәтне фотога төшерү.

3) таләпләрне бозып урнаштырылган күчмә сәүдә объектын ачыклау турында акт күчермәсе, күрсәтмә күчермәсе

____________________________________________________________________ районы хакимияте вәкиле
(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза, имза расшифровкасы)

Күчмә сәүдә объекты милекчесе (хуҗасы) ______________________________________________________
(Ф.И.А.и., имза, имза расшифровкасы)

Шаһит 1: ____________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Шаһит 2: ____________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., имзаны теркәү урыны, имза расшифровкасы)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева